ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Муниципаль хезмәт турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2015, 7 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында "югары һөнәри" сүзләрен "югары" сүзенә, "югары яисә" сүзләрен "югары белем яисә" сүзләренә алмаштырырга;

2) 13 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында "квалификациясен арттырырга" сүзләрен "өстәмә һөнәри белем алырга" сүзләренә алмаштырырга;

3) 15 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында "комачауларлык һәм" сүзләреннән соң "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон нигезендә" сүзләрен өстәргә;

4) 21 статьяның 4 өлешендә "квалификацияләрен күтәрергә" сүзләрен "өстәмә һөнәри белем алу өчен" сүзләренә алмаштырырга;

5) 30 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"1. Муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгару календарь тәртибендә башкарыла, мондый исәпләүгә гражданнарның чакырылыш буенча хәрби хезмәт узу вакыты керми, ул исә хәрби хезмәтнең бер көне өчен ике эш көне буларак исәпләнә. Муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгарганда хезмәт (эш) чорлары бергә кушыла.";

6) түбәндәге эчтәлекле 34[1] статья өстәргә:

“34[1] статья. **Муниципаль хезмәт өчен кадрларны шартнамә нигезендә әзерләү**

1. Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын булдыру максатларында җирле үзидарә органнары, мәгариф турында Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәт өчен гражданнарны шартнамә нигезендә әзерләүне оештыра алалар.

2. Укып бетергәч муниципаль хезмәт узу йөкләмәсен алып максатчан уку турында шартнамә (алга таба – максатчан уку турында шартнамә) җирле үзидарә органы белән граждан арасында төзелә һәм уку тәмамланганнан соң гражданның күрсәтелгән җирле үзидарә органында билгеләнгән срок дәвамында муниципаль хезмәт узу буенча йөкләмә алуын күз алдында тота.

3. Максатчан уку турында шартнамә төзү конкурс нигезендә башкарыла.

4. Конкурс җирле үзидарә органы тарафыннан игълан ителә һәм җирле үзидарә органында төзелә торган конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

5. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат муниципаль хокукый актлар рәсми басылып чыга торган басма массакүләм мәгълүмат чарасында күрсәтелгән конкурсны үткәрү датасына кимендә бер ай кала басылып чыгарга һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтына урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендә каралган конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта граждан уку тәмамланганнан соң белеп торырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфаларының төркемнәре; шул вазыйфаларга карата квалификация таләпләре; әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә конкурска тапшырыла торган документларның исемлеге; аларны кабул итү урыны һәм вакыты; күрсәтелгән документлар кабул итүнең чик вакыты; конкурс үткәрү датасы, урыны һәм тәртибе күрсәтелә, шулай ук мәгълүмат бирүче башка материаллар күрсәтелгән булырга мөмкин.

7. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурста Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән беренче тапкыр урта һөнәри һәм югары белемне көндезге уку рәвешендә алучы гражданнар катнашырга хокуклы. Күрсәтелгән конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә кергәндә, шулай ук әлеге статьяның 14 өлешендә каралган бөтен срок дәвамында “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль закон белән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләп тору өчен каралган таләпләргә туры килергә тиеш.

8. Конкурста катнашырга теләк белдергән граждан җирле үзидарә органына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхси гаризаны;

2) муниципаль хезмәткә керә торган граждан тарафыннан җирле үзидарә органына тапшыру өчен федераль законнар нигезендә расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетаны, аңа фоторәсем кушып бирелә;

3) паспорт күчермәсен (паспорт конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

4) хезмәт кенәгәсенең күчермәсен яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документларны (хезмәт эшчәнлеге элек башкарылмаган очраклардан тыш);

5) гражданның "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәткә керүенә һәм аны узуына каршы килә торган авыруы булмау хакында медицина оешмасы бәяләмәсен;

6) гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчалары исәбеннән беренче тапкыр урта һөнәри яисә югары белемне көндезге уку рәвешендә алуын раслый торган, шулай ук ул үзләштерә торган уку-укыту программасы турында (һөнәрнең, белгечлекнең исемен яисә әзерлек юнәлешен күрсәтеп), уку планы нигезендә гражданның урта аттестация узу нәтиҗәләре хакында, мәгариф оешмасының уставында һәм эчке тәртип кагыйдәләрендә каралган йөкләмәләрнең аның тарафыннан үтәлүе турында мәгълүматны үз эченә алган мәгариф оешмасы белешмәсен.

9. Персональ мәгълүматларның һәм әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә граждан тарафыннан тапшырылган документларга кертелгән башка белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча тикшерелергә мөмкин.

10. Конкурс комиссиясе дәгъва итүчеләргә әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән тапшырылган документларга нигезләнеп, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәя бирә. Конкурс процедураларына әңгәмә, анкета тутыру, тест эшләү, язма биремнәр эшләү һәм федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларга каршы килми торган башка процедуралар җирле үзидарә органы карары буенча кертелергә мөмкин.

11. Конкурс комиссиясе муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы муниципаль хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә утырышлар үткәрә һәм максатчан уку турында шартнамә төзү хакында карар кабул итә.

12. Конкурста катнашкан гражданнарга конкурс тәмамланган көннән соң бер ай эчендә язма рәвештә нәтиҗәләр турында хәбәр ителә.

13. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына транспортта бару һәм кире кайту, торак урынын наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәт күрсәтүләреннән файдалану һәм башкалар) гражданнарның үз акчалары исәбеннән тотыла.

14. Максатчан уку тәмамланганнан соң муниципаль хезмәтне мәҗбүри узу срогы максатчан уку турындагы шартнамәдә билгеләнә. Күрсәтелгән срок максатчан уку турында шартнамә нигезендә гражданга җирле үзидарә органы тарафыннан социаль ярдәм чаралары күрсәтелгән сроктан ким була алмый, әмма ул биш елдан күбрәк булырга тиеш түгел.

15. Максатчан уку турында шартнамә якларының йөкләмәләре һәм җаваплылыгы максатчан уку турында шартнамәдә Россия Федерациясе законнарына туры китереп билгеләнә.

16. Максатчан уку турында шартнамә граждан белән бер генә тапкыр төзелә ала.

17. Максатчан уку турында шартнамәдә каралган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.";

7) 38 статьяның 3 пунктында "муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү" сүзләрен "муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләү һәм муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү" сүзләренә алмаштырырга;

8) 4 нче кушымтада:

а) 18 пунктның 3 пунктчасында "квалификация күтәрү" сүзләрен "өстәмә һөнәри белемне уңышлы алу" сүзләренә алмаштырырга;

б) 21 пунктның 2 пунктчасында "квалификация күтәрүгә" сүзләрен "өстәмә һөнәри белем алу өчен" сүзләренә алмаштырырга;

в) 22 пунктта "квалификация күтәрүдән" сүзләрен "өстәмә һөнәри белем алудан" сүзләренә алмаштырырга;

г) Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында үрнәк нигезләмәгә кушымтаның 10 пунктында "квалификация күтәрү" сүзләрен "өстәмә һөнәри белемне уңышлы алу" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2015 елның 21 июле
№ 61-ТРЗ